| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » 10 2021 № 321

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклandыруны оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, укучыларның балансланган туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 21.09.2020 ел, № 851 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1 Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Аксубай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч сыйныф укучыларын бер тапкыр бушлай кайнар аш белән тәэмин итү өчен Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең унай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе раслаган ике атналык унике көнлек (алты көнлек) цикллы менюга (кайнар иртәнге ашларга) туры китереп, Аксубай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч сыйныф укучыларын бер тапкыр бушлай кайнар аш белән тәэмин итүне 53 сум 41 тиенгә оештырырга.

1.2. 5-11 сыйныф мәгариф учреждениеләре укучылары өчен бер уку көненә укучыларны бушлай туклandыруны оештыруга каралган 8 сум 00 тиен күләмендә субсидияләр, мәктәп яны участогыннан керемнәр һәм ата-аналар түләвеннән кергән, 2.3/2.4.3590-20 СанПиН № 12 кушымта нигезендә кайнар аш (иртәнге яки төшке аш) оештырырга кирәк.

1.3. Үз составында 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм инвалид балалар булган гаиләләрдәге 5-11 сыйныф укучыларын 30 сум 00 тиеннән дә ким булмаган (шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджетыннан укучыларның бер уку көненә түләүсез туклануын оештыруга каралган 8 сум 00 тиен субсидия, Аксубай муниципаль районы бюджетыннан укучыларның күрсәтелгән категориясен туклануны оештыруга 22 сум) кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга

1.4. Укучыларга бушлай туклану бирү буенча комиссия төзергә, аның составы учреждение директоры тарафыннан раслана. Комиссия составына тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, туклануны оештыру өчен җаваплы ата-

аналар комитеты вәкилен кертергә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

1.5.Өй формасында укучы 5-11 сыйныф укучылары өчен азык-төлек җыелмасы аена бер тапкыр (бер айга уку көннәре санын исәпләгәндә бер балага 30 сум 00 тиеннән дә ким булмаган суммага 20-нче числосыннан да соңга калмыйча) бирергә

2. Мәктәп ашханәсендә туклануны уникe көнлек меню буенча җитештерергә.

3. Аксубай муниципаль районының Финанс бюджет палатасына 4 һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар  һәм инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрдән балаларны бушлай тукландыруны оештыру өчен матди мөмкинлекләр табарга. (1нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә куркынычсыз, сыйфатлы, рациональ, баланслы тукылануны тәэмин итүне, әзер ризыкларның сыйфатын, әзерләү технологияләренең үтәлешен, санитар – гигиеник таләпләрнең үтәлешен, балаларны тукландыруны тикшереп торуны объектив тикшерү максатларында бракераж комиссиясе төзергә.

5. Гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануны оештырган өчен ата-аналар түләвеннән тулысынча яки өлешчә азат итү турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, СТБДМС (ЕГИСО) операторы билгеләгән формалар нигезендә, Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - СТБДМС) урнаштырылырга тиеш.

6. Гомуми белем бирү оешмаларында кайнар ашны оештырган өчен ата-аналар түләвеннән тулысынча яки өлешчә азат итү турында мәгълүмат социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (СТБДМС) куллану чаралары буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.

7. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы мәгариф оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2019 ел, 28 декабрь, 932 нче карары (31.08.2020, № 564а, 18.01.2019, № 8, 14.10.2020, № 648, 25.12.2020, № 796, №50карлары) үз көчен югалткан дип санарга.

8. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга .

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе С.Ю.Зайцев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ОГРН 1061665000650 ИНН 1603004720 КПП 160301001

Татарстан Республикасы

Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.10.2021 № 321 карарына
1 нче кушымта

Аксубай районының белем бирү оешмаларында 2021 елның 1 сентябреннән түләүсез тукландыруны оештыру өчен үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм инвалид балалар булган гаиләләрдәге укучылар саны турында

МӘГЪЛҮМАТ

| № т/б | Мәгариф учреждениесенең исеме | МУндә балаларның гомуми саны | 4 һәм аннан да күбрәк бала | | Инвалид балалар һәм мөмкинлекләре чикләнгән балалар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | семей | в них детей | |
| 1. | «2 нче Аксубай УГБМ» МБМУ | 347 | 17 | 22 | 1 |
| 2. | «3 нче Аксубай УГБМ» МБМУ | 728 | 20 | 26 | 2 |
| 3. | «В. Г.Тимирясов исемендәге 1 нче Аксубай УГБМ» МБМУ | 337 | 12 | 23 | 1 |
| 4. | «Емелькино УГБМ» МБМУ | 56 | - | - | 1 |
| 5. | Г. Г. Романов исемендәге Кәкре Күл УГБМ МБМУ | 56 | 8 | 13 | 2 |
| 6. | «Түбән Татар Майнасы УГБМ» МБМУ | 51 | 4 | 9 | - |
| 7. | «Яңа Ибрай УГБМ» МБМУ | 55 | 1 | 2 | - |
| 8. | «Савгач УГБМ» МБМУ | 187 | 2 | 6 | 3 |
| 9. | «Иске Ибрай УГБМ» МБМУ | 157 | 6 | 13 | - |
| 10. | «Иске Илтерәк УГБМ» МБМУ | 98 | 4 | 8 | 2 |